СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон (8552) 70-00-33, факс 70-12-61, tukay.rt@tatar.ru

31.08.2026 № 13/4

На № ________ от ____________

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 39/5 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 11 декабрендәге 01-09-28994 номерлы хатын, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 12 ноябрендәге 1621/о номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, муниципаль район Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 29 ноябрендәге 39/5 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга һәм «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе

К.Р. Нәҗмиев